| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07-05-2020 г.Лениногорск № 57

2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында Лениногорск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында

Россия Федерациясе Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыру хакында » 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру хакында»2020 елның 24 апрелендәге УП-250 номерлы Указы, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Лениногорск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чоры өчен, Лениногорск муниципаль районы башлыгы вазыйфасына эшкә килә торган зат тарафыннан, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшыру турында «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгының 2014 елның 29 августындагы

158 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә билгеләнгән белешмәләрне тапшыру срогын кертеп, 2020 елның 1 августына кадәр озайтырга.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы аппараты җитәкчесе Н.Г. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Р.Г.Хөсәенов

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72